ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.05.2019 Казан ш. № 142

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 20 октябрендәге 284 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 20 октябрендәге 284 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы территориясендә товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, хак арттыруларны һ.б.) дәүләти җайга салу өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм тормышка ашырганда гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләткә карамаган коммерциясез бүтән оешмаларның хокукларын яклау;

Дәүләт комитеты эшчәнлеге өлкәсенә кагыла торган мәсьәләләрдә дәүләт сәясәтендәге төп юнәлешләрне эшләү буенча иҗтимагый, һөнәри һәм иҗат берләшмәләре вәкилләрен җәлеп итү, Дәүләт комитеты эшчәнлелегендә хәбәрдарлык һәм ачык булу принцибын тормышка ашыру;

2.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Иҗтимагый советның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы территориясендә бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, хак арттыруларны һ.б.) дәүләти җайга салу өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы территориясендә товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, хак арттыруларны һ.б.) дәүләти җайга салу өлкәсенә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан әзерләнә торган дәүләт программалары проектлары буенча фикер алышу;

Дәүләт комитеты карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Дәүләт комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлыгын арттыру;

җәмгыятьтә коррупциячел торышка сабырсызлык формалаштыру.»;

5.12 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары нигезендә, Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый советта каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциячел булмаган оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.12.1 пункт өстәргә:

«5.12.1. Иҗтимагый совет үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының катнашуын тәэмин итә.».

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис А.С.Груничев